**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**«18» май 2023 ел** **№ 109**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 03 декабрь 2021 ел, № 55 механизмарга үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 03 декабрь 2021 ел, № 55 карарына Татарстан транспорт прокуратурасының 21.02.2023 ел, №23/1-12-23 дәгъвасы белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 3 өлешенә яраштырып, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 03 декабрь 2021 ел, № 55 карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 37 нчы пунктның 5 нче пунктчасында «һәм тимер юлның» сүзләрен алып ташларга;

2) 68 нче пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга;

3) 69 нчы пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга;

4) 70 нче пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин